БАВЛИНСКОГО БАСМАСЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНА

БАУЛЫ РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЛАР СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

13.03.2025 ел Баулы шәһәре № 299

«Баулы муниципаль районы территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында» Баулы муниципаль район Советының 2021 елның 14 декабрендәге 94 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 540-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Баулы муниципаль районы территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында» Баулы муниципаль район Советының 2021 елның 14 декабрендәге 94 номерлы карарына (2022 елның 11 апрелендәге 111 номерлы, 2023 елның 20 июнендәге 190 номерлы, 2023 елның 26 октябрендәге 225 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 255 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Баулы муниципаль районы территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәдә:

2.11 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Профилактик визит, контрольдә тотыла торган зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча инспектор тарафыннан кисәтү әңгәмәсе рәвешендә, йә «Инспектор» видео-конференция-элемтә яисә мобиль кушымтасыннан файдалану юлы белән уздырыла»;

3.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Планнан тыш күчмә тикшерү, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә аны үткәрү очракларыннан тыш, прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин.»;

3.18 пунктның 1 пунктчасында «ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә» сүзләреннән соң «мәҗбүри таләпләр» сүзләрен өстәргә, «һәм (яисә) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерүне булдырмау чараларын үткәрү турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.11. Шикаять, контроль орган тарафыннан, аны судка кадәр шикаять бирү системасында теркәгән көннән алып, унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш.

Контрольдә тотылучы затның контроль объектларын хәвеф-хәтәрнең тиешле категориясенә кертү турындагы карарга шикаяте биш эш көненнән дә соңга калмыйча карала.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль район Советының икътисадый үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе И.И. Гозәеров